ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/14

Шәһәр Советының даими комиссияләр турындагы Нигезнамәсенә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикася Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының даими комиссияләре турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2014 елның 10 июлендәге 31/22, 2015 елның 17 декабрендәге 4/14, 2018 елның 10 августындагы 26/15 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 10 маддәдә:

- икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«- шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен кабул итү һәм аны гамәлгә ашыруны оештыру;»;

- 10 абзацны көчен югалткан дип танырга;

2) 11 маддәнең 18 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

3) 12 маддәнең 24 абзацында «гавами тыңлаулар,» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышулар,» сүзләрен өстәргә;

4) 14 маддәдә:

- бишенче абзацны «,шул исәптән, аларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән чараларны да кертеп;» сүзләре белән тулыландырырга;

- 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирле шартларны һәм мөмкинлекләрне исәпкә алып, физик культура һәм спортны үстерүнең төп бурычларын һәм юнәлешләрен билгеләү, физик культура һәм спортны үстерү буенча җирле программаларны кабул итү һәм гамәлгә ашыру; мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү;».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев